ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 05.03.2025 461 **КАРАР**

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган, яки контракт буенча хәрби хезмәт узучы, ирекле ярдәм турында контракт төзегән гражданнарының гаиләләренә өстәмә ярдәм чаралары хакында» 2023 елның 6 июнендәге 802 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләре һәм махсус хәрби операциядә катнашу аркасында һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы карары нигезендә, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган, яки контракт буенча хәрби хезмәт узучы, ирекле ярдәм турында контракт төзегән гражданнарының гаиләләренә өстәмә ярдәм чаралары хакында» 2023 елның 6 июнендәге 802 номерлы карарына түбәндзге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Әлеге карарның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1. «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган, яки контракт буенча хәрби хезмәт узучы, ирекле ярдәм турында контракт төзегән гражданнарының (алга таба - хәрби хезмәткәрләр), хәрби хезмәткәрләрнең, әгәр хәрби хезмәт узу чорында яки аннан эштән китү яки контракт туктатылганнан соң аларга имгәнүдән (яраланудан, травма, контузия алудан) инвалидлык билгеләнгән яки авыру алынган булса, сугыш хәрәкәтләре ветераннары һәм

инвалидлары, шулай ук махсус хәрби операция нәтиҗәсендә һәлак булганнарның гаиләләренә өстәмә ярдәм итүнең түбәндәге чараларын расларга:».

1. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 4DF13A255AE51927759AA463F36F11E0
Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна
Действителен с 09.01.2025 до 04.04.2026

Э.Р. Әхмәдиева